**КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ**

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2016 ел, 2 сентябрь № 612

г. Казань

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы территориясендә урнашкан күпфатирлы йортлардагы уртак мөлкәтне капиталь ремонтлау буенча региональ программаны раслау турында» 2013 ел, 31 декабрь, 1146 нчы карарына үзгәрешләр кертү хакында

«Россия Федерациясе Торак кодексына һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 2015 елның 29 июнендәге 176-ФЗ номерлы Федераль законның 12 статьясындагы 12 өлеш нигезендә Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы территориясендә урнашкан күпфатирлы йортлардагы уртак мөлкәтне капиталь ремонтлау буенча региональ программаны раслау турында» 2013 ел, 31 декабрь, 1146 нчы карарына (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2015 ел, 22 гыйнвар, 29 нчы карары белән кертелгән үзгәрешне исәпкә алып) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

әлеге карар белән расланган Татарстан Республикасы территориясендә урнашкан күпфатирлы йортлардагы уртак мөлкәтне капиталь ремонтлау буенча региональ программаны яңа редакциядә бәян итәргә (теркәлгән);

2 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2. Күпфатирлы йортлардагы уртак мөлкәтне капиталь ремонтлау фондын формалаштыру ысулын билгеләү турында карар, «Татарстан Республикасында күпфатирлы йортларда гомуми мөлкәткә капиталь ремонт ясауны оештыру турында» 2013 елның 25 июнендәге 52-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 2 статьясындагы $4^1$ өлеш белән билгеләнгән очрактан тыш,

Программаны рәсми бастырып чыгарган көннән соң 45 көн эчендә күпфатирлы йортлардагы бүлмәләр милекчеләре тарафыннан кабул ителергә һәм тормышка ашырылырга тиеш, дип билгеләргә.».

Татарстан Республикасы
Премьер-министры И.Ш.Халиков